КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 5 сентябрь г.Казань № 774

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 31 декабрь, 1100 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 31 декабрь, 1100 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 9 март, 133 нче; 2016 ел, 8 май, 286 нчы; 2016 ел, 21 июнь, 419 нчы; 2016 ел, 4 октябрь, 715 нче; 2016 ел, 22 декабрь, 968 нче; 2017 ел, 6 июнь, 345 нче; 2017 ел, 21 ноябрь, 894 нче; 2017 ел, 30 декабрь, 1133 нче; 2019 ел, 16 февраль, 111 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

V бүлекнең 5.4 бүлекчәсендәге 5.4.2 нче пунктында:

беренче абзацта «30 эш көненә кадәр» сүзләрен – «21 эш көненә кадәр» сүзләренә, «21 эш көне» сүзләрен «15 эш көне» сүзләренә алыштырырга;

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә, мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләрендә стационар формада социаль хезмәт күрсәтү вакыты инвалидны (инвалид баланы) тернәкләндерү яки абилитацияләү буенча индивидуаль программада тормыш эшчәнлегенең төп категорияләренең 2, 3 дәрәҗәдәге чикләүләре булган инвалидлар, инвалид балалар өчен инвалидның (аның законлы вәкиленең), инвалид баланың законлы вәкиленең социаль хезмәт күрсәтү вакыты чыкканга кадәр социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүченең эш көннәрендә исәпләнә торган 5 көннән дә соңга калмыйча тапшырылган тиешле гаризасы нигезендә озайтыла (әмма социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүченең эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көннән дә артыкка түгел).»;

әлеге тәртипкә теркәлгән 4 нче кушымтаның «Инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә, мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләрендә, халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча комплекслы үзәкләрнең социаль-тернәкләнерү бүлекләрендә социаль хезмәтләр күрсәтү исемнәре, тасвирламасы һәм аларны социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыларга (гаиләдә даими рәвештә чит кеше каравына мохтаҗ инвалид (инвалид бала) булуга бәйле рәвештә социаль хезмәтләр күрсәтүгә мохтаҗ дип танылган гражданнардан тыш) аларны социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында күрсәтү күләмнәре» дигән таблицасындагы 5.1 нче пунктның 2 графасындагы текст башына «14 яшькә җиткән файдаланучылар белән» сүзләрен өстәргә.

2. Бу карар 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин